**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

## КАРАРЫ

**2015 елның «30» декабреннән** **№ 8-27**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»на үзгәрешләр кертү турында»**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге 89 –ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 8 статьясынигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы,

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясындагы 30 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «муниципаль район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итү, муниципаль районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга: «муниципаль район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итү, муниципаль

районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясындагы 1 өлешенең 8 пунктын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга: «дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 76 ст. 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә: «хокукый акт яки хокукый акт текстын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштыру»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 90 статьясы атамасына «һәм муниципаль контрольнең башка төрләре» сүзләрен өстәргә;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 90 статьясына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктны өстәргә:

- Муниципаль контрольнең башка төрләре:

- муниципаль торак контроле;

- муниципаль җир контроле;

- муниципаль район территориясендә ваклап сату базарында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;

- алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендә законнарның үтәлешен контрольдә тоту;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп тору.

- муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларны координацияләү һәм аларны үткәрүне контрольдә тоту;

- гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм аларны саклауны контрольдә тоту;

- муниципаль район территориясендә җәзалар үтәтүче учреждениеләр һәм тикшерү изоляторлары эшчәнлеген Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә тотуны тикшереп тору.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарының әлеге проектын кабул итәргә һәм халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

3. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча 2016 елның 11 гыйнварында сәг. 14.00 дә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы,80 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында ачык тыңлаулар үткәрергә.

Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе Яңа Чишмә муниципаль районының 2006 елның 23 ноябрендәге 10-81 номерлы карары белән расланган, 2006 елның 29 ноябрендә «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасының 116 номерында басылып чыккан гавами тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә башкарыла.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә гавәми тыңлауларда яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләренең мәгълүмат стендларында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» игълан итәргә (бастырырга).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**